**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“30” март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы “2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (бензин белән эшли торган кар чистарткыч сатып алу; Күәм авылы территориясен чистарту (агач һәм куаклар кисү) эш һәм хезмәт өчен түләү);
2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (вак таш сатып алу, Күәм авылы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү);
3) Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (Күәм авылы зираты территориясен чистарту (агач һәм куаклар кисү), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).”

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Хасбиуллин И.И.

АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОГРН 1021606157627 ИНН 1610000525
Совет Кубянского сельского поселения
Күәм авыл җирлеге Советы